Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXIX-8**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 19 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 апрелендәге 8 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 29.10.2022 ел № XXVII-5 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 4 маддәдә:

5 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлектәге ярдәмче абзацны өстәргә:

«капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтенә таләпләр;»;

түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

«12. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтенә таләпләр капиталь төзелеш объектының күләм-пространство (киңлек), архитектура-стилистик һәм башка сыйфатламаларына, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган таләпләрне үз эченә ала.»;

– 12 нче пунктны тиңдәшле рәвештә 13 нче пункт дип санарга;

1.1) 27 маддәдә:

– 5 пунктның 3 пунктчасында «проект» сүзен «Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15 өлеше нигезендә расланган проект» сүзләренә алмаштырырга;

– 5 пунктның 4 пунктчасында «проект» сүзен «Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15 өлеше нигезендә расланган проект» сүзләренә алмаштырырга;

- 5 пунктның 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 4.1, 4.2 пунктчалар өстәргә:

«4.1) проект документациясенә кертелә торган проект документациясен әзерләүче затлар әгъзалыгына нигезләнгән, үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан һәм әлеге зат Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлауны оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган зат тарафыннан тәкъдим ителгән үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау проект документациясенә Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 өлеше нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта;

4.2) проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау, ул башкарма хакимият органы яисә проект документациясенә экспертиза уздырган оешма тарафыннан бирелгән, шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.9 өлеше нигезендә эксперт озата бару (бергә теркәп җибәрү) барышында проект документациясенә үзгәрешләр кертелгән очракта;

5 пунктта түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү, әгәр мондый килештерү Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса;»;

1.2) 28 маддәдә:

– 5 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә» сүзләрен «әлеге Кодекс нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә каралган тәртиптә..» сүзләренә алмаштырырга;

– 7 пунктта «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен өстәргә;

1.3) 29 маддәнең 3 пунктының 2, 4, 6 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

-30 маддәнең 12 пунктында «ике айдан да ким булмаган һәм дүрт айдан да артык булмаган» сүзләрен «бер айдан да артык булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов